**СОВЕТ ЧИРПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422615, с. Чирпы,
ул. Молодежная, д.4а
тел: 2-91-45

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРПЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422615, Чирпы авылы,
Яшьләр урамы, 4а нчы йорт,
тел: 2-91-45

**№ 5** **2019 елның 4 апреленнән**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәп буенча вәкаләтләр башкаручы хәрби-исәп хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында**

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәп буенча вәкаләтләр башкаручы хәрби-исәп хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен һәм хезмәтенә түләүне тәртипкә салуны тәэмин итү максатыннан һәм Россия Федерациясе оборона министрлыгының 2014 елның 23 апреленнән №255 (2016 елның 18 августы редакциясендә, 2018 елның 30 гыйнварыннан үзгәртүләр белән) “Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 5 августыннан №583” (“Россия Федерациясе хәрби частьләре һәм кораллы көчләре оешмалары гражданлык персоналы хезмәтенә түләү системасы турында Кагыйдә”, (“Россия Федерациясе хәрби частьләре һәм кораллы көчләре оешмалары гражданлык персоналы хезмәтенә түләү фондын формалаштыру һәм файдалану Тәртибе” белән бергә) карарын тормышка ашыру буенча чаралар турында” Боерыгына нигезләнеп, Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәп буенча вәкаләтләр башкаручы хәрби-исәп хезмәткәрләре (алга таба – хәрби-исәп хезмәткәрләре) хезмәт хакы хезмәттәге айлык окладтан, хезмәттәге окладка хезмәттәге еллары өчен айлык өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча премиядән, аерым климатик шартлы (район коэффициентында) җирлектә эшләү өчен түләүләрдән, календарь ел йомгаклары буенча вазифаи бурычларын намуслы башкарган өчен акчалата бүләктән тора дип билгеләргә.
2. Хәрби-исәп хезмәткәрләренең вазифаи оклады Россия Федерациясе оборона Министрлыгының 2014 елның 23 апреленнән №255 “Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 5 августыннан №583”

“инспектор” дәрәҗәсе буенча” карарын тормышка ашыру буенча чаралар турында” боерыгына ярашлы төстә билгеләнә һәм 6552 сум тәшкил итә дип расларга.

3. Хәрби-исәп хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) вазифаи окладка хезмәттәге еллар өчен айлык өстәмә түбәндәге күләмдә:

| эш стажы түбәндәгечә | процентларда |
|---|---|
| 1 елдан артык | 5; |
| 2 елдан артык | 10; |
| 3 елдан артык | 15; |
| 5 елдан артык | 20; |
| 10 елдан артык | 30; |
| 15 елдан артык | 40. |

2) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премия (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге күрсәткечләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләме чикләнми).

Ай (квартал, ел) өчен эш кәрсәткечләре буенча премия түләү хезмәткә түләү фондының бу максатларга каралган акчалар чикләрендә башкарыла.

3) аерым климатик шартлы (район коэффициентында) җирлектә эшләү өчен түләүне исәпләнгән хезмәт хакыныә гомуми суммасыннан 1,15 күләмендә билгеләргә.

4) вазифаи бурычларны намуслы башкару өчен акчалата бүләкләү елына 2 вазифаи окладка кадәр.

Хезмәткәргә түләнә торган бүләк күләме аңа бүләкләү түләнүче календарь елның 1 декабренә биләгән вазифасы буенча билгеләнгән ике вазифаи окладтан артык була алмый, күтәрелүләрне дә исәпкә алып, ә эштән киткән кешегә ел дәвамында - эштән киткән көненә.

4. Шуны билгеләргә:

хәрби-исәп хезмәткәрләренең вазифаи окладлары, шулай ук айлык һәм башка түләүләр күләме үстерү ягына таба тулы сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш.

5. Бу карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварына булган хокук мөнәсәбәтләренә караганлыкны билгеләргә.

6. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - Лаеш муниципаль районы**
**Чирпы авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Р.А.Евдокимов**